ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль, 2018 ел № 23/10

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсеше турында» 209-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече, урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алынган мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 159-ФЗ санлы Федераль закон, 2006 елның 26 июлендәге «Конкурентлыкны яклау турында» 135-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 21 августындагы «Федераль мөлкәт тапшырганда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү хакында» 645 санлы Карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге 25/5 санлы Карары белән кабул ителгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 22.10.2009 № 43/9, 26.05.2010 № 50/8, 15.12.2011 № 15/9, 20.04.2012 № 18/8, 15.04.2015 № 39/11 Карарлары редакциясендә), 19 бүлекне яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«19 бүлек. Өченче затлар хокукыннан азат булган (урта һәм кече эшмәкәрлек субьектларының мөлкәти хокукларыннан башка) муниципаль мөлкәтне формалаштыру, алып бару һәм муниципаль мөлкәт исемлеген рәсми бастыру тәртибе.)

98. Өченче затлар хокукыннан азат булган муниципаль мөлкәт (урта һәм кече эшмәкәрлек субьектларының мөлкәти хокукларыннан башка) исемлеген формалаштыру, раслау, алып бару һәм муниципаль мөлкәт исемлеген рәсми бастыру (алга таба – Исемлек), шулай ук аңа үзгәрешләр кертү Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

99. Исемлеккә түбәндәге критерийларга туры килгән муниципаль мөлкәт хакында мәгълүматлар кертелә:

1) өченче затлар хокукыннан азат булган (урта һәм кече эшмәкәрлек субьектларының мөлкәти хокукларыннан башка) муниципаль мөлкәт;

2) әйләнештә чикләнмәгән муниципаль мөлкәт;

3) дини кулланылыш обьекты булмаган муниципаль мөлкәт;

4) төзелеп бетмәгән төзелеш объект булып саналмаган муниципаль мөлкәт;

5) муниципаль мөлкәтне башка затларга бирү турында карар булмаган муниципаль мөлкәт;

6) Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә булып, Яр Чаллы шәһәр муниципаль милкен Хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) кертелмәгән муниципаль мөлкәт;

7) авария хәлендә дип танылмаган, җимерү яки реконструкция үткәрү каралмаган муниципаль мөлкәт.

100. Муниципаль мөлкәт турында мәгълүматларны Исемлеккә кертү (шул исәптән, Исемлекне ел саен тулыланлырып тору), шулай ук мәгълүматларны Исемлектән алу Башкарма комитет яки кече һәм урта эшмәкәрлек субьекты, кече һәм урта эшмәкәрлек субьектларына теләктәшлек күрсәтү инфраструктураларын булдыручы оешмалар (алга таба – Субьект) тәкъдиме белән Башкарма комитет карары нигезендә гамәлгә куела.

101. Исемлекне формалаштыру белән кызыксынган субьектларның тәкъдимнәре, кабул ителгән көннән алып, 30 календарь көне эчендә карала:

1) әлеге Нигезнамәнең 99 пунктында каралган критерийларга туры килүен исәпкә алып, муниципаль мөлкәтне Исемлеккә кертергә

2) әлеге Нигезнамәнең 104 һәм 105 пунктларында каралган критерийларга туры килүен исәпкә алып, муниципаль мөлкәтне Исемлектән алырга;

3) тәкъдимне исәпкә алмаска.

102. Әлеге Нигезнамәнең 101 пункты, 3 пунктчасында каралган тәртиптә карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет мәгълүматны муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертү яйсә Исемлектән алу хакында тәкъдим керткән затка нигезле җавап бирергә тиеш.

103. Башкарма комитет инициативасы белән Исемлеккә үзгәрешләр кертү агымдагы елның беренче ноябреннән дә соңга калмыйча башкарыла.

104. Муниципаль мөлкәт турындагы Исемлектәге мәгълүмат хакында ике ел дәвамында Субъекттан хәбәр булмаганда:

1) муниципаль мөлкәтне арендага алу хокукына ия булу өчен уздырылучы аукционда (алга таба – Аукцион) катнашуга бер тапкыр да гариза белән мөрәҗәгать итмәгән очракта,

2) 2006 елның 26 июлендәге «Конкурентлыкны яклау турында» 135- ФЗ санлы Федераль законында каралган тәртиптә муниципаль мөлкәтне Аукционнан башка килешү нигезендә бирүне сорап бер тапкыр да гариза белән мөрәҗәгать итмәгән очракта,

Башкарма комитет муниципаль мөлкәт турындагы Исемлектән мәгълүматны алырга хокуклы.

105. Башкарма комитет муниципаль мөлкәт хакындагы мәгълүматларны Исемлектән түбәндәге очракта ала:

1) мөлкәтнең алга таба билгеләнгән максатта кулланырга мөмкин булмаган халәттәге сыйфат характеристикалары үзгәрүе;

2) муниципаль мөлкәтнең юкка чыгуы;

3) әлеге мөлкәтне муниципалитет ихтыяҗлары өчен файдалану хаҗәте барлыкка килү;

4) суд карары яисә закон белән билгеләнгән башка тәртиптә мөлкәтнең муниципаль мөлкәт хокукын югалтуы.

106. Исемлеккә муниципаль мөлкәт турында мәгълүматлар Россия Федерациясе законнары белән каралган составта һәм формада кертелә.

107. Исемлекне алып бару Башкарма комитет тарафыннан электрон формада башкарыла.

108. Исемлек һәм аңа кертелгән үзгәрешләр рәсми бастырылырга тиеш. Рәсми бастыру вакыты: рәсми басмаларда - расланган көннән алып 10 эш көнендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында – расланган көннән алып 3 эш көнендә.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев